ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2023 г. Казань № 718-43/тко-2023

«Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә Көнбатыш эшчәнлек зонасы буенча төбәк операторы хезмәтенә 2024 елга чик дәрәҗә бердәм тарифлар билгеләү турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 15.12.2023 №59-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлегенең Көнбатыш зонасы буенча төбәк операторы хезмәтенә әлеге карар кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә бердәм тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чик дәрәҗә бердәм тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлегенең Көнбатыш зонасы буенча төбәк операторына ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 23 гыйнварындагы 109 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу

стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2023 № 718-43/тко-2023
карарына кушымта

«Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә Көнбатыш эшчәнлек зонасы буенча төбәк операторы хезмәтенә 2024 елга календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә бердәм тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәте күрсәтүгә чик бердәм тарифлар, сум/куб.метр | |
|---|---|---|---|
| | | 2024 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| 1 | «Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән) | 528,44 | 549,58 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге